**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КИЛЬДЮШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

422387 с. Кильдюшево, ул. Молодёжная, 22

422387 Килдеш авылы, Яшьләр урамы, 22

тел. (84373) 5-22-66,e-mail: Kld.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559325, ИНН/КПП 1638001590/163801001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 .11. 2023** **№ 31-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Килдеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проекты турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Килдеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Килдеш авыл җирлеге Советына таянып Татарстан карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Килдеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының тәкъдим ителгән проектын (алга таба – Устав проекты) беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Устав проекты буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның катнашу тәртибен 4 нче кушымта нигезендә расларга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Килдеш авылы, Яшьләр урамы, 22 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru.
7. Килдеш авыл мәдәният йорты бинасында Устав проекты буенча 2023 елның 22 декабренә 14:00 сәгатьтә ачык тыңлаулар билгеләргә.
8. Устав проекты буенча Комиссиягә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Килдеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә ачык тыңлаулар турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә Устав проектын тикшерү һәм килгән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль

районы Килдеш авыл җирлеге Башлыгы В.С. Исаевка йөкләргә.

**Җитәкче** **В.С. Исаев**